РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛКОМ СТАРО-ИМЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА
ул. М. Вахитова дом 36в с. Старый Имян,
423373, телефон, (85559) 4-34-68

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ИМЭН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Иске Имән авылы, М. Вахитов урамы, 36в
423373, телефон (85559) 4-34-68

ОГРН 1061687003080 ИНН/КПП 1636005599/163601001 ОКТМО 92653470

---

**КАРАР**
21 июль 2015 ел

**КАРАР**
№6

Иске Имән авыл жирлеге башкарма комитетының 2015 елга наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм прекурсорларның законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү буенча чаралар планын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 09.06.2010 ел, № 690 Указы белән расланган"Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында" 08.08.1988 ел, № 3-ФЗ Федераль законның 7 ст. 2 өлеше нигезендә, 2020 елга кадәр Россия Федерациясе Дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясенең 9 п. "з" пунктчасы белән, Иске Имән авыл жирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Иске Имән авыл жирлеге башкарма комитетының наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм прекурсорларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү буенча 2015 елга чаралар планын расларга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга. PRAVO.TATARSTAN.RU( Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл жирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ә.Исламова

Иске Имән башкарма комитеты
авыл җирлеге башлыгының 6 нчы номерлы
карарына кушымта
25 июль 2015 ел

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитетының наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм прекурсорларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү буенча 2015 елга чаралар планы

| № п/п | Чараның исеме | Үтәү вакты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлеге каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекторлар, җирле профилактика органнары белән балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру, хокук бозуларга дучар булган затларны, имин булмаган гаиләләрне ачыклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |
| 2 | Хокук бозуларга дучар булган затлар белән аңлату характерындагы шәхси әңгәмәләр үткәрү | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килешү буенча) |
| 3 | Мәдәният учреждениеләренә (клубларга) Спектакльләр, концертлар, башка театр-тамаша һәм күргәзмә чаралары үткәрүдә, халыкның төрле төркемнәренең ялын | даими | Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оештыруда, тормышка ашыруда ярдәм итү<br>башка төр мәдәни - иҗади, мәдәни-танып-белү, ял итү һәм башка төр эшчәнлек | | |
| 4 | Халык бәйрәмнәрен оештыруда катнашу | айлык бәйрәмнәрен вакытында үткәрүне тәэмин итә торган сроклар | Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 5 | Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, Физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре буенча иҗтимагый оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 6 | Алкоголизм һәм наркоманиядән интегүче затлар белән аңлату характерындагы шәхси әңгәмәләр үткәрү | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, «Сарман үзәк район хастаханәсе» ДАССОның фельдшер-акушерлык пунктының медицина шәфкать туташы (килешү буенча) |
| 7 | Халыкка хокук бозулар һәм җинаятьләр кылган өчен җаваплылык турында, шул исәптән мәгълүмати стендлар аша хәбәр итү | даими | Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 8 | Авыл советы территориясендә ел дәвамында җинаятьчелек дәрәҗәсен киметүне тәэмин итү буенча кирәкле комплекслы оештыру чаралары үткәрү | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килешү буенча) |
| 9 | Балигъ булмаган хокук бозучылар, социаль-куркыныч хәлдәге балалар, белем бирү | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | учреждениеләренә йөрмәүче балалар, опека һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат җыю, анализлау һәм гомумиләштерүнең бердәм системасын формалаштыру | | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килешү буенча) |
| 10 | Авыл җирлеге башкарма комитеты утырышларында муниципаль берәмлектә җинаятьчелек һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен, шул исәптән хокук саклау органнары вәкилләрен карау | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 11 | Физик затлар белән индивидуаль-профилактик һәм реабилитация эшләре үткәрү:<br>- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән;<br>- шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр тарафыннан иректән мәхрүм итү белән бәйле җәза чараларына карата;<br>- аларга карата хөкем карарын үтәү кичектерелде;<br>- җәмәгать яисә административ йогынты чараларын кулланып яисә амнистия акты нәтиҗәсендә җинаять кылган, әмма җинаять җаваплылыгыннан азат ителгән.;<br>- иҗтимагый яки административ йогынты чаралары китерә торган хокук бозулар кылган затлар;<br>- алкогольле һәм/яки спиртлы продукцияне чамадан тыш кулланучылар | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килешү буенча) |
| 12 | Балалар җинаятьчелеген профилактикалау мәсьәләләре буенча белем бирү учреждениеләрендә катнашу | даими | Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |